| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 декабрь 2019 ел № 37

Иске Иштирәк авыл җирлегендә янгынга каршы
махсус режим урнаштыру турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре вакытында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, физик һәм юридик затлар, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең сакланышын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 30 статьясы һәм 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII Татарстан Республикасының “Янгын куркынычсызлыгы турында” Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 3 декабрендәге “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында” 913 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында" 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карарының 13 пункты нигезендә, «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 декабреннән 2020 елның 10 гыйнварына кадәр Иске Иштирәк авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.
2. Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорына җирлек башлыгы Мәҗитов Н.Ә. җитәкчелегендә ирекле янгын дружинасы әгъзаларыннан профилактика төркеме төзергә (1 нче кушымта).
3. Профилактик төркемгә торак йортларда гражданнар белән профилактик әңгәмәләр үткәрүне оештырырга, шул ук вакытта күп балалы гаиләләрнең, ялгыз картларның һәм имин булмаган гражданнарның яшәү урыннарына аерым игътибар бирергә кирәк. Моның өчен билгеләнмәгән урыннарда пиротехник эшләнмәләрне ачыклау һәм сатуны тыю, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне РФ законнары белән билгеләнгән тиешле сертификатлардан башка сату эшен

чикләүне оештырырга. Хезмәт күрсәтүче персоналга инструктаж үткәрергә, Яңа ел һәм Раштуа чараларын үткәрү урыннарын контрольгә алырга.

4. Хезмәт күрсәтүче персоналга инструктаж үткәрү белән Яңа ел һәм Раштуа чараларын үткәрү урыннарын контрольгә алырга.

5. Фейерверклар үткәрү урыны итеп Иске Иштирәк авыл җирлеге халкы һәм кунаклары өчен Школьнкая урамы, 15нче йорт (авыл мәдәният йорты каршында) буенча ачык мәйданчыкны билгеләргә.

6. Пиротехник эшләнмәләрне түбәндәге урыннарда куллану тыела**:**

а) теләсә кайсы функциональ билгеләнештәге биналарда, биналарда һәм корылмаларда;

б) шартлау куркынычы булган һәм янгын куркынычы янаган объектлар территорияләрендә, тимер юлларны, нефтьүткәргечләрне, газ үткәргечләрне һәм югары вольтлы электр линияләрен читкә чыгару полосаларында;

в) түбәләрдә, балконнарда, биналарның лоджияләре һәм чыгып торучы урыннарында;

г) сәхнә мәйданчыкларында, стадионнарда һәм башка спорт корылмаларында;

д) митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру вакытында;

е) Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектлары, тарих һәм мәдәният һәйкәлләре, зиратлар һәм дини корылмалар, тыюлыклар һәм милли парклар территорияләрендә.

8. ТМШ рәисенә торак йортларның подвалларына үтеп керүне чикләү буенча чаралар күрергә.

Җирлек башлыгына җирлек территориясендә урнашкан гидрантларның техник торышын тикшерергә.

9.Әлеге карарны Иске Иштирәк авылы Школьная урамы, 15нче йорт, Ялтау урамы, тынычлык урамы, 27, Бәкер авылы Нагорная 38 адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам..

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Ә.Мәҗитов

Кушымта 1
ТР ЛМР «Иске Иштирәк авыл җирлеге»
башкарма комитеты карарына 12.12.2019 ел, №37

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге буенча профилактик төркем
СОСТАВЫ

1. Мәҗитов Нашат Әхәтович – җирлек башлыгы,
2. Шиапов Ришат Энзирович – ДПД әгъзасы,
3. Насыров Серин Әхтәмович –ДПД әгъзасы ,
4. Шәвәлиев Илдус Габделәхәтович –ДПД әгъзасы ,
5. Низамов Фәнил Ялалтдинович –ДПД әгъзасы ,
6. Әхмәтшин Рәфгат Мәүлетҗанович –ДПД әгъзасы,
7. Иванов Виталий Егорович – ДПД әгъзасы ,
8. Вәлиәхмәтов Айрат Атласович – ДПД әгъзасы,
9. Кашапов Фәнис Касыймович – ДПД әгъзасы.
10. Шакиров Искандәр Мөдәрисович – ДПД әгъзасы
11. Мөхәмәтов Серин Рәфкатович – ДПД әгъзасы
12. Галяутдинов Булат Рәисович – ДПД әгъзасы
13. Гайфуллин Рафис Расимович – ДПД әгъзасы
14. Юнысов Марат Илгизович – ДПД әгъзасы
15. Сәхаув Ришат Илгизәрович – ДПД әгъзасы